| | |
|---|---|
| **СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ИВАНОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИВАНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

**2018 елның 14 декабре**

**№31**

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 03 октябрендәге 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарының үтәлешен тикшереп торуны камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 31 октябрендәге 382-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 03.10.2016 № 35 номерлы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 6.4 пункт өстәргә:

«Җитәкче булып торучы муниципаль хезмәткәр җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорда тапшыра алмый.»;

7.1 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) шәхси яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерцияле оешма белән идарә итүдә яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдән тыш ;һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында булдырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән түләүсез идарә итүдә катнашырга; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу; күрсәтелгән коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партия һәм һөнәри берлек органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органыннан тыш) тарафыннан бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез идарә итүдә яки аларның коллегиаль идарә органнары составына кергәндә яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән алынган, муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән), оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш, гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек муниципаль берәмлек исеменнән оешманың оештыручысы яисә муниципаль милектә булган акцияләр белән идарә итү вәкаләтләрен башкару тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә (устав капиталында катнашу өлешләре); федераль законнарда каралган башка очракларда;».

2.Ивановка авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

«Ивановка авыл җирлеге»

муниципаль берәмлеге

башлыгы,

совет рәисе А.П. Бодряева